| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.03.2023 Казан ш. № 621-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында" 19.12.2015 № 3233-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында», 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм «Основание» кадастр үзәге» ААҖ әзерләгән документациягә туры китереп, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУ (05.03.2024 № 04А-08/546) хатын күздә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында” 19.12.2015 № 3233-р карары (алга таба - № 3233-р Карар) белән урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге, “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә булган 19043 инвентарь номерлы, 16:50-6.1736 реестр номерлы газ бүлү газүткәргеченең 16:50:280818:103 кадастр номерлы җир кишәрлегендәге ПРГ үзгәртелү, трасса үзгәртелү аркасында газ үткәргечләре күчерелү сәбәпле саклау зонасына, «Основание» кадастр үзәге» ААҖ әзерләгән җир өсте һәм җир асты объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә туры китереп үзгәрешләр кертергә. Газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы гомуми мәйданы (260638 ± 179) кв.м булып, 29630 м озынлыкны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 19043 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, «Основание» кадастр үзәге» ААҖ әзерләгән газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3233-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.01.2017 № 107-р, 22.06.2017 № 1378-р, 13.07.2017 № 1608-р, 29.08.2017 № 1977-р, 28.09.2017 № 2191-р, 22.09.2017 № 2155-р, 22.08.2018 № 2563-р, 31.08.2018 № 2653-р, 05.12.2018 № 4140-р, 25.06.2019 № 1970-р, 07.08.2019 № 2419-р, 05.11.2019 № 3520-р, 21.01.2020 № 117-р, 25.10.2021 № 3236-р, 28.12.2021 № 4111-р, 14.06.2022 № 1741-р, 22.08.2022 № 2447-р, 05.07.2023 № 1849-р, 06.12.2023 № 3416-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казан ш. (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) территориясендә урнашкан 1 452,98419 км озынлыктагы, ЭПУ «Казаньгоргаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) 6,31206798 кв.км мәйданны тәшкил иткән саклау зоналары чикләрен «Рубикон» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ, «ГеоПроект» ҖЧҖ, «Казан ш.нең җир-инвестиция агентлыгы» ҖЧҖ, «АллЮр» ҖЧҖ, «Основание» кадастр үзәге» ААҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты

объектларының саклау зоналарына картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә расларга.»;

1 нче кушымтада инвентарь номеры 19043 булган газүткәргечкә туры килгән юлны әлеге карарга кушымтадагы редакциядә бәян итәргә (бастыру каралмаган).

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**